Кабул ителде Раслыйм

| | |
|---|---|
| Педагогик киңәшмәнең карары | 4-нче балалар бакчасы мөдире |
| Беркетмә № | Г.Я.Низамова |
| “16” август 2024 ел | “16” август 2024 ел |

# Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Лениногорск шәһәренең “4 нче балалар бакчасы” муниципаль бюджет мәктәпкәчә тәрбия бирү учреждениесының федераль укыту- тәрбия программасы нигезендә төзелгән 2024– 2025 нче уку елына еллык эш планы проекты

Лениногорск 2024

Кабул ителде Раслыйм

| | |
|---|---|
| Педагогик киңәшмәнең карары | 4-нче балалар бакчасы мөдире |
| Беркетмә № | Г.Я.Низамова |
| “16” август 2024 ел | “16” август 2024 ел |

# Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Лениногорск шәһәренең “4 нче балалар бакчасы” муниципаль бюджет мәктәпкәчә тәрбия бирү учреждениесының федераль укыту- тәрбия программасы нигезендә төзелгән 2024– 2025 нче уку елына еллык эш планы проекты

Лениногорск 2024

**2023-2024 нче уку елында эшләнгән эшләргә анализ**

Узган уку елында бакчада 80 бала тәрбияләнде, 5 төркем эшләде. Балаларга белем-тәрбия бирүдә, кызыксынучанлыкларын, фикерләү сәләтләрен үстерүдә, чисталыкка–пөхтәлеккә өйрәтүдә 11 педагог көч куйды.

| № п п | Ф И О | Вазифа | Педагогик стаж | Диплом, белеме |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Низамова Гөлфия Яхия кызы | Мөдир | 45 ел | Югары, КСЮИ, 2004ел ВСБ №0959291,Педагог-психолог |
| 2. | Вәлиуллина Зилия Тахир кызы | Тәрбияче | 14 ел | Югары «КФУ» , 2013 ел КУ № 40635, бакалавр |
| 3. | Гиззатуллина Регина Ригель кызы | Музыка җитәкчесе | 13 ел | Югары, КФУ, 2013ел, КП № 97496, Музыка җитәкчесе<br>Урта, ЛМХПК, 2010, Музыка җитәкчесе. |
| 4. | Галеева Светлана Виктор кызы | Тәрбияче | 26 ел | Югары, ВЭГУ, 2013ел КН № 45916, Организатор-методист дошкольного образования |
| 5. | Симонова Ландыш Рассам кызы | Тәрбияче | 37 ел | Махсус урта, ЛПУ,1986ел ,ИТ №273908, Музыка тәрбиячесе һәм җыр укытучысы |
| 6. | Минязева Гөлия Әбузар кызы | Тәрбияче | 34 ел | Махсус урта, БПУ2001ел, СБ№1218716, Балалар бакчасы тәрбиячесе; Югары, ВЭГУ 2017 ел, 130205 0318099, бакалавр. |
| 7. | Миндиярова Галия Рафаэль кызы | Тәрбияче | 30 ел | Махсус урта, НПУ,1993ел, СТ №225300, Балалар бакчасы тәрбиячесе; Югары, ВЭГУ 2016 ел, 130205 317129, бакалавр. |
| 8. | Насрутдинова Әлфия Айрат кызы | Тәрбияче | 32 ел | Югары, ВЭГУ, 2013ел, КН №45937, Организатор-методист дошкольного образования |
| 9. | Гарипова Сания Тәлгать кызы | Тәрбияче | 34 ел | Югары, ВЭГУ,2013ел, КН № 45922, Организатор-методист дошкольного образования |
| 10 | Мөслихова Гөлфия Фәрит кызы | Тәрбияче | 34 ел | Махсус урта, НПУ, 1989ел, МТ №402028, Балалар бакчасы тәрбиячесе; Югары, ВЭГУ 2016 ел, бакалавр. |
| 11. | Миназова Элвира Масхут кызы | Тәрбияче | 26 ел | Югары, КСЮИ, 2004ел ВСБ 095928 Педагог-психолог |
| 12. | Хасанова Гузәл Өлфәт кызы | Педагог-психолог | 2 ел | Югары, ИЭУП, 2017 ел, 252-Н(б), бакалавр;<br>ИЭУП, 2022 ел, ДП-20- 2022-А, Педагог- психолог. |
| | | | | |

**Педагогик стаж:**

- 5 елга кадәр– 1 кеше;
- 15 елга кадәр– 3кеше
- 10 елга кадәр– 1кеше;
- 15 елдан артык–10 кеше

**Диагностика нәтиҗәләре**

Балаларның уку программасын үзләштерүенә чагыштырма анализ

| Уку елы | Балалар саны | Уку программасын үзләштерү дәрәҗәсе | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Югары % | Урта % | Түбән % |
| **2017-2018** | 69 | 39 (56%) | 28 (41%) | 2 (3%) |
| **2018-2019** | 106 | 56 (50%) | 47 (46%) | 3 (4%) |
| **2019-2020** | 106 | 58 (55%) | 46 (43%) | 2 (2%) |
| **2020-2022** | 106 | 68 (64%) | 38 (36%) | 0 |
| **2021-2022** | 95 | 55 (57%) | 42 (41%) | 3 (2%) |
| **2022-2023** | 85 | 57 (56%) | 40 (38%) | 3(2%) |
| **2023-2024** | 80 | 66(66%) | 32(32%) | 2 |

**Балалар сәамәтлегенә нәтиҗә ясау**

Балаларны барлык табиплар нәтиҗәләреннән һәм лаборатория тикшеренүләреннән соң, балалар саулык төркемнәрендә бүленде:

| Саулык группасы | 2020-2021 уку елы | 2021-2022 уку елы | 2022-2023 уку елы | 2023-2024 уку елы |
|---|---|---|---|---|
| Балалар саны | 106 | 95 | 85 | 80 |
| 1 | 50 | 53 | 54 | 54 |
| 2 | 54 | 51 | 56 | 24 |
| 3 | 2 | 2 | 1 | 2 |
| 4 | - | - | - | - |

Бер баланың авыру сәбәпле килмәгән көннәр саны – 4,2
Сәламәтлек индексы:

| 2020-2021 уку елы | 2021-2022 уку елы | 2022-2023 уку елы | 2023-2024 |
|---|---|---|---|
| 52% | 58% | 57% | 54% |

Балаларының сәламәтлеген саклау, ныгыту хәзерге көндә ата-аналарны, педагогларны иң борчыган мәсәләләрнең берсе. Шуннан чыгып алдыбызга түбәндәге мәсьәләләрне куйдык:

- хәрәкәт - бала өчен иң кирәкле шарт булуын күз уңында тотып, бакчада хәрәкәтле уеннарны үз югарылыгында уздыру;
- туклану - бала организмы өчен иң мөһиме шарт, шуңа күрә менюны сәламәтлекне саклау технологиясенә нигезләнеп төзү;
- организмны чыныктыру нәтиҗәсендә баланың салкынга, эссегә, авыруларга каршы торучанлыгын арттыру, чыныктыруны һәр балаларның үзенчәлекләрен искә алып оештыру;
- балаларның бакчадан тыш вакытын дөрес оештыру буенча ата-аналар белән әңгәмәләр үткәрү;
- мәктәпкәчә яшьтәге балачак - сабыйның психик үсешендәге беренче чор, чөнки бу яшьтә шәхеснең бөтен психик сыйфатларына һәм үзенчәлекләренә нигез салына. Шуларны истә тотып, баланың һәрьяклакп үсеше өчен гаиләнең тәрбияче белән үзара аңлашып, ярдәмләшеп эшләвен булдыру.

Кыскасы, балаларны сәламәт рухта тәрбияләү – балалар бакчасының изге бурычы, чөнки балаларның күп вакыты бакчада уза, ул аларның икенче өе булып тора. Шунлыктан бакчада нәниләр өчен барлык уңай шартларны тудырырга тырыштык. Балаларның сәламәтлеген саклау, ныгыту, аларның физик һәм интеллектуаль үсешен тәэмин итү йөзеннән, эшебезне планлаштырудан башладык, планнарны балалар бакчасының эшен камилләштерү буенча үзгәрешләр кертеп һәм яңа бурычлар куеп оештырдык. Яшь үзенчәлекләренә туры китереп һәр төркемдә чыныктыру планы төзелде, аның буенча эш оештырылды; сәламәтлек почмаклары, спорт мәйданчыгы ясалды.Балалар мәйданчыгы

да төрле атрибутлар белән җиһазларландырылды, экскурсияләр оештырлды, анда дару үләннәре турында әңгәмәләр үткәрелде, үләннәрне таныргa өйрәтелде; хәрәкәтле уеннар өчен кулланма җиһазлар тупланды; спорт төрләрен кулланып бәйрәмнәр, хәрәкәтләнү күнекмәләрен үстерү буенча күңел ачу кичәләре уздырылды. Тәрбиячеләребез көндәлек режимны төгәл үтәп, белем-тәрбия бирү эшен дөрес оештырды. Иртәнге гимнастика, физик тәрбия шөгыльләре ел буена программага нигезләнеп, тиешле дәрәҗәдә алып барылды. Физик тәрбия шөгыльләрендә иң беренче балаларның активлыгына игътибар ителде, дәрес уздыру төрләре үзгәртелде, яңалыклар кулланылды.

Бакчада физкультура шөгеле уртанчылар,зурлар һәм мәктәпкә хәзерлек төркемнәрендә өч тапкыр уздырылды - шөгелнең берсе, һава торышы уңай булганда, ачык һавада уздырылды.

Менюда ризыклар төрләндерелде, балалар аксымга бай продуктлар, үз бакчабызда үстерелгән яшелчә белән тукландырылды.

Бакчада ел буена көндәлек режим төгәл үтәлде, йоклар алдыннан аяк кулларны юу, йокыдан торгач балаларның күңелен күтәрү, чыныктыру күнегүләре эшләтелде. Һәр төркемдә буш вакытларда даими рәвештә күз гимнастикасы, аваз әйтү гимнастикалары кертелде.

Дөрес туклану, көндәлек режимны, сәламәтлек программасын төгәл үтәү, физкультура, спорт белән даими шөгыльләнү, организмны чыныктыру балаларыбыз сәламәтлегенә уңай тәэсир итте: алар азрак авырды.

**Бакчабызның бурычы –“ Балаларга әхлакый-патриотик тәрбия бирү, үз халкың белән горурлану хисе тәрбияләү”.**

Патриотизм хисе эчтәлеге буенча күпкырлы: туган якка мәхәббәт, үз халкың белән горурлану, үз илеңнең байлыгын арттыру һәм аны сакларга теләк булдыру һ.б.

Шулай итеп, әлеге эш бербөтен максатлар комплексын үз эченә ала:

- балада үз гаиләсенә карата мәхәббәт тәрбияләү, шулай ук үз йортына, балалар бакчасына, урамына, авылына (шәһәренә);
- табигатькә һәм барлык тереклек ияләренә сак караш формалаштыру;
- татар (рус һ.б.) халык традицияләренә һәм йолаларына карата кызыксынучанлыкны үстерү;
- кеше хокуклары турында элементар белем формалаштыру;
- Татарстан (Русия һ.б.) шәһәрләре турында күзаллауны киңәйтү;
- хөкүмәт символлары (*герб, флаг, гимн*) белән таныштыру;
- үз республикаңның уңышлары өчен горурлану һәм җаваплылык хисен үстерү;
- толерантлык, башка халыкларга, аларның традицияләренә карата хөрмәт хисе формалаштыру.

Бу максатлар балаларның барлык эшчәнлек төрләрендә үтәлә: шөгыльләрдә, уеннарда, хезмәт эшчәнлегендә, көнкүрештә - чөнки алар балада патриотик хисләр тәрбияләү белән бергә аның өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән үзара мөнәсәбәтләрен дә формалаштыралар.

**Бакчабызның икенче бурычы: “Татар халык авыз иҗаты аша балаларның сөйләм телен үстерү, тел кимчелекләрен бетерү”.** Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны халык авыз иҗаты әсәрләре белән тел үстерү чаралары вакытында да, уйнаганда да таныштырырга була. Җанлы һәм тапкыр сүзле мәкаль әйтемнәр, сынамыш, такмак, табышмак, әкиятләр балаларда тел матурлыгын тоемлау тәрбиялиләр, танып белү эшчәнлеген сөйләм телен үстерәләр. Халык авыз иҗаты әсәрләренең тәрбияви әһәмияте аеруча зур.

Башлангыч класска кергәндә бала сөйләмендә кимчелекләр булмаска тиеш. Ел буена авазларны, сүзләрне дөрес әйтү культурасын тәрбияләү, үз фикерләрен, кичерешләрен аңлатканда җөмләләрне тел нормаларына туры китереп, ачык, дөрес әйтү, дөрес дикция белән сөйләшергә өйрәтү өчен балаларга төрле күнегүләр өйрәттеләр, ата-аналарга киңәшләр бирделәр, аларны ачык дәресләргә чакырдылар. Барлык балаларның да ике телне дә яхшы белүе мөһим. Балалар бакчаларына дәүләт телләрен өйрәтү өчен укыту-методика комплекты төзелгән, тәрбиячеләр һәм ата-аналар өчен матур әдәбият җыентыклары, шулай ук татар һәм рус телләрендәге аудио- видеоматериаллардан торган комплектлар кайтарылды. Тәрбиячеләр эшләрендә методик ярдәмлекләрне кулландылар. Ике дәүләт телен өйрәнүне тормышка ашыруны мәктәпкәчә яшьтән өйрәтә башлау зур әһәмияткә ия.Чөнки балалар бакчасында балаларның һәрьяклы үсешенә нигез салына,сөйләм культурасы формалаша,коммуникатив күнекмәләр үстерелә. Театральләштерелгән уеннар һәм күңел ачу кичәләрендә русча сөйләү күнекмәләре ныгытыла.

**Балаларга тәрбия һәм белем бирү эшен анализлау**

Балалар бакчасы ел буе балаларга эзлекле белем бирү, физик яктан чыныккан, сәламәт, табигатьне саклый белүче балалар тәрбияләү бурычлары өстендә эшләде. Белем һәм тәрбия бирүнең беренче баскычы булган мәктәпкәчә тәрбия бирү учреждениеләренең эшен нәтиҗәле итү өчен яңа идеяләр, белем-тәрбия бирүдә инновацион технологияләр куллану кирәк.
Безнең балалар бакчасы педагоглары яшь буынны тәрбияләүдә яңа чаралар, белем-тәрбия бирүнең нәтиҗәле методларын табып, кулланып, зур уңышларга ирештеләр. Бакчада балаларның физик, интеллектуаль һәм шәхси үсешен тәэмин итү, иҗат мөмкинлекләрен ачу һәм үстерүгә нык игьтибар ителде. Тәрбиячеләр балаларга белем-тәрбия бирүдә заман таләпләренә туры килә торган программаларга нигезләнеп эшләделәр. ***Бу программалар үз алдына балаларны бар яклап та сәламәт шәхес итеп үстерү, аңа мәктәптә уку–тәрбия алу өчен кирәкле психологик процесслар булдыруны максат итеп куя.***

Тәрбияче тарафыннан балалар бакчасының укыту-тәрбия планнары, шөгыльләр чилтәре һәм календарь планнары төзелде, бакча мөдире тарафыннан расланды һәм гамәлгә кертелде. Ел дәвамында шул шөгыльләр чилтәре буенча тәрбиячеләр даими рәвештә балалар белән шөгыльләр алып бардылар. Мәктәпнең башлангыч сыйныф укытучылары белән ныклы элемтәдә торабыз: алар гомуми киңәшмәләрдә, ата-аналар җыелышларында катнашалар.

**Балалар бакчасында кулланылган программалар:**

**Төп өлеше:**

Мәктәпкәчә төп белем бирү программасы Татарстан Республикасы “Лениногорск муниципаль районы” берәмлеге муниципаль “Лениногорск шәһәренең 4 санлы балалар бакчасы” муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе өчен федераль белем бирү программасы документы.

**Вариатив өлеш:**

- Изучаем русский язык: программа, авт.-сост.: С. М. Гаффарова, Ч. Р. Гаффарова, Г. З. Гарафиева-Казань, 2013
- Программа “Светофор” – Т. И. Данилова, СПб. 2009
- Семьеведение: учебно-методическое пособие для педагогов системыдошкольного образования Карцева, Л.В.Казань: 2016.
- Формирование антикоррупционного мировоззрения детей старшего дошкольного возраста (5-7 лет) в условиях реализации требований федерального государственного образовательного стандарта дошкольного образования: учебно-методический комплект для специалистов дошкольного образования и родителей. – Руднева Я. Б., Казань: 2015.
- «От рождения до школы»- основная обрзовательная программадошкольного образования. Н.Е. Вераксы, Т.С. Комаровой, М.А. Васильевой «Мозаика- Синтез» Москва, 2016.
- “Туган телдә сөйләшәбез” – методическое пособие для 1 младшей группы авт. Ф.В. Хазратов ., Казан, 2013.
- “Туган телдә сөйләшәбез”- методическое пособие для второй младшей группы авт. Ф.В. Хазратов, Казан, 2013.
- “Туган телдә сөйләшәбез” методическое пособие для средней группы, авт. Ф.В. Хазратова, Казан, 2013.
- “Туган телдә сөйләшәбез” методическое пособие для детей 5-7 лет. авт. З.М.Зарипова., Казан, 2013.
- «Сөенеч» – «Радость познания» - региональная образовательная программа дошкольного образования. Авт. Шаехова Р.К. “Магариф-Вакыт”. Казань, 2016 г.
- “Физкультурные занятия в детском саду” Л.И.Пензулаевой, “Мозайка- Синтез”, 2009.
- «Формирование элементарных математических представлений», И.А.Помараевой, В.А.Позина «Мозайка- Синтез», 2014.
- «Ознакомление с природой в детском саду» О.А. Соломенниковой, “Мозайка синтез”, 2014.
- «Изобразительная деятельность в детском саду» Т.С.Комарова, «Мозаика синтаз» 2014.

**Төркемнәрдә җаваплы кешеләр**

| № | Исем, фамилиясе | Төркем исеме | Белеме | Категориясе |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Хасанова Гүзәл Өлфәт кызы | Беренче кечкенәләр төркеме тәрбиячесе | югары | СЗД |
| 2. | Симонова Ландыш Рассамовна | Икенче кечкенәләр һәм уртанчылар төркемнәре тәрбиячесе | урта | 1 квалификацион категория |
| 3. | МиндияроваГалия Рафаэловна | Беренче кечкенәләр тәрбиячесе | югары | Югары квалификацион категория |
| 4. | Насрутдинова Әлфия Айратовна | Зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркеме тәрбиячесе | югары | 1 квалификацион категория |
| 5. | Мөслихова Гөлфия Фаритовна | Икенче кечкенәләр төркеме тәрбиячесе | югары | Югары квалификацион категория |
| 6. | Миназова Эльвира Масхутовна | Зурлар төркеме тәрбиячесе | югары | 1 квалификацион категория |
| 7. | Гарипова Сания Талгатовна | Уртанчылартөркеме тәрбиячесе | югары | 1 квалификацион категория |
| 8. | Минязева Гөлия Әбузровна | Мәктәпкә әзерлек төркеме тәрбиячесе | югары | 1 квалификацион категория |

**Балалар бакчасының 2024- 2025 уку елы төп бурычлары:**

1. Балаларның индивидуаль сәләтләрен һәм ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) ихтыяҗларын исәпкә алып, мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирүнең яңа оештыру-педагогик формаларын һәм методларын эшләү һәм гамәлгә кертү;
2. Балаларның сәламәтлеген саклау, ныгыту, аларның физик һәм психик үсеше өчен мөмкинлекләр тудыру.;
3. Интернационализм, толерантлык сыйфатларын кулланып балаларга әхлак һәм патриотик тәрбия бирүне дәвам итү;
4. Милли- региональ компонентка таянып, милли мәдәниятне белүче һәм дәвам итүче шәхес формалаштыру:
5. Милли кыйммәтләрне саклау мәсьәләләрендә гаилә һәм балалар бакчасының үзара хезмәттәшлеген ныгыту;

**Консультацияләр, әңгәмәләр**

| | Эшләнәчәк эш төре | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләүдә гаилә һәм балалар бакчасының үзара мөнәсәбәте. | Сентябрь | Минязева Г.А. |
| 2 | Гаиләдә һәм балалар бакчасында әхлак тәрбиясе. | Декабрь | Муслихова Г.Ф. |
| 3 | Гаилә традицияләренең бала шәхесен формалаштыруга йогынтысы. | Октябрь | Хасанова Г.Ө. |
| 4 | Мәктәпкәчә яшьтәге баланың тулы үсешенә заманча телекоммуникацияләрнең йогынтысы. | Январь | Насрутдинова А.А. |
| 5 | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга патриотик тәрбия бирү системасында заманча технологияләр. | Апрель | Миназова Э.М. |

**Методик эш**

| № | Эш төрләре | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше | Үтәлеш |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Бакчаны педагогик кадрлар белән тәэмин итү. | август | Мөдир | |
| 2 | Бакчаны яңа уку елына әзерләү. | август | Мөдир, өлкән тәрбияче | |
| 3 | 2023-2024 нче уку елындагы эшчәнлеккә анализ ясау. Бакчаның еллык белем-тәрбия планын төзү, кабул итү. | август сентябрь | Мөдир, өлкән тәрбияче | |
| 4 | Хезмәткәрләрнең хезмәт бүленешен раслау. | август сентябрь | Мөдир | |
| 5 | Төркем бүленешен, шөгыльләр челтәрен төзү, раслау. | август сентябрь | Мөдир,өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр | |
| 6 | Педагогик кафедра утырышларында катнашу | даими | Мөдир, өлкәнтәрбияче, тәрбиячеләр | |
| 7 | Муниципаль конкурсларда катнашу | УО планы буенча | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр | |
| 8 | Мәктәп белән балалар бакчасы арасындагы дәвамчанлыкны үстерү | даими | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр, мәктәп | |
| 9 | Уен почмакларын балаларның яшь үзенчәлекләрен истә тотып кирәкле уенчыклар белән тулыландыру. | ел дәвамында | Мөдир, өлкән тәрбияче | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 10 | Методик кабинетны яңа методик әсбәпләр, күрсәтмә материаллар, белән тулыландырып тору, баету буенча эшләү | даими | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр | |
| 11 | Эш юнәлешләре буенча тәрбиячеләрнең портфолиоларын тулыландыруны барлау. | ел дәвамында | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр | |
| 12 | Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү буенча альбом, кулланма җиһазлар булдыру, тулыландыру. | сентябрь | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр | |
| 13 | Экологик тәрбия буенча кулланма һәм күргәзмә әсбаплар булдыру. | даими | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр | |
| 14 | Бүлмәләрдә гөлләр үстерү, балаларга күзәтү өчен үсемлекләр утырту. | даими, яз аенда | Тәрбиячеләр, тәрбияче ярдәмчеләре | |
| 15 | Балаларны районыбызның, җирлегебезнең данлыклы шәхесләре белән таныштыру өчен материаллар туплауны дәвам итү | даими | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр | |
| 16 | Дидактик, өстәл уеннарын яңарту, тулыландыру. | даими | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр | |
| 17 | Халкыбыз тарихы – борынгы әйберләр белән таныштыру өчен материаллар белән тулыландыру(музей өчен) | даими | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр | |
| 18 | Балалар бакчалары арасында үткәрелүче конкурсларда катнашу. | даими | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр | |

**Ачык шөгыльләр**

| **№** | **Эшләнәчәк эш төре** | **Вакыты** | **Җаваплы** | **Үтәлеш** |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Танып белү (рәсем) | Апрель | Насрутдинова А.А. | |
| 3. | Танып белү (әвәләү) | Ноябрь | Муслихова Г.Ф. | |
| 4 | Ана теле | Февраль | Минязева Г.А. | |
| 5 | Хәрәкәт эшчәнлеге | Октябрь | Гарипова С.Т. | |
| 6. | Рус теле | Ноябрь | Галеева С.В. | |

## Алдынгы педагогик тәҗрибәне гомумиләштерү, тарату

| | Эш төре | Җаваплы кешеләр | Үтәү вакыты | Үтәлеш |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Район күләмендә үткәрелгән ММО утырышларында, семинарларда катнашу, тәҗрибә уртаклашу буенча чыгышлар ясау. | Мөдир, өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр | даими | |
| 2 | Интернет публикацияләре аша үзләренең эш тәҗрибәсен тарату. | Мөдир, өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр | даими | |
| 3 | Тәрбиячеләрнең эш тәҗрибәсен өйрәнү, районга тарату чараларын күрү, шулай ук онлайн эшчәнлекне арттыру. | Мөдир, өлкән тәрбияче | ел дәвамында | |
| 4 | Тәрбиячеләрнең эш тәҗрибәсе буенча брошюралар ясау һәм таратуда матбугат чараларыннан һәм интернеттан файдалану. | Мөдир, өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр | ел дәвамында | |

## Педагогик киңәшмәләр

| № | Эш төре | Үтәү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1-нче киңәшмә | **Темасы “Яңа уку елына әзерлек”** | август | Өлкән тәрбияче |
| | 1. Җәйге эшкә анализ. | | төркем тәрбиячеләре |
| | 2. Яңа уку елына балалар бакчасының әзерлеге торышы | | Мөдир |
| | 3. Еллык укыту-тәрбия эш планын тәкъдим итү. Еллык календарь планын раслау.<br>Перспектив планнарны тәкъдим итү. | | Өлкән тәрбияче,тәрбиячеләр |
| | 4. Шөгыльләр бүленешен һәм көндәлек режимны тәкъдим итү. | | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | 5. Хезмәткәрләрнең хезмәт бүленешен раслау, тарификация белән таныштыру. | | Мөдир |
| | 6. Төрледән | | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 2- нче киңәшмә | **Тема: «Милли кыйммәтләрне саклау мәсьәләләрендә гаилә һәм балалар бакчасының үзара хезмәттәшлеге»** | Ноябрь | Өлкән тәрбияче |
| | 1. 2 нче педсовет карарларын үтәү. | | Өлкән тәрбияче, төркем тәрбиячеләре |
| | 2. Алдагы киңәшмәдә кабул иткән карар үтәлешенә анализ. | | Өлкән тәрбияче |
| | 3. “Гаилә- бала тормышында шәхси тәрбия алу мөхите” | | Насрутдинова А.А. |
| | 4. “Ныклы гаилә- ныклы дәүләт” | | Муслихова Г.Ф. |
| | 5. Кечкенәләр төркемнәрендә адаптация үтүгә анализ. | | Миндиярова Г.Р. |
| 3 нче киңәшмә | **Тема: “Балалар бакчасында патриотик тәрбия бирү юллары”** | Январь | |
| | 1. Алдагы киңәшмәдә кабул иткән карар үтәлешенә анализ. | | Өлкән тәрбияче<br>Һәр төркем тәрбиячесе |
| | 2. Балаларга патриотик тәрбия бирүдә татар халык йолалары, бәйрәмнәре, традицияләр куллану. | | Муслихова Г.Ф. |
| | 3. С.Сайдашев әсәрләре аша балаларда патриотик һәм толерантлылык хисләре тәрбияләү. | | Гиззатуллина Р.Р. |
| | 4. “Мәктәпкәчә яштәге балаларга патриотик тәрбия бирү системасында заманча технологияләр” | | Миназова Э.М. |
| | 5. Педсовет карарын тикшерү һәм кабул итү. | | Өлкән тәрбияче тәрбиячеләр |
| 4-нче киңәшм | **Тема: “Татар халык авыз иҗаты аша балаларның сөйләм телен үстерү.** | апрель | |
| | 1. Алдагы киңәшмәдә кабул иткән карар үтәлешенә анализ. | | Өлкән тәрбияче , тәрбиячеләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 2. Сәхнәләштерү эшчәнлеге аша балаларның сөйләм телен үстерү. | | Галеева С.В. |
| | **3.** Халык авыз иҗаты әсәрләренең сөйләм телен үстерүдәге әһәмияте. | | Хасанова Г.А. |
| | 4. Балаларның сөйләм телен үстерүдә җырлы- биюле уеннарның әһәмияте. | | Гиззатуллина Р.Р. |
| | 5. Педсовет карарын тикшерү һәм кабул итү. | | Өлкән тәрбияче , тәрбиячеләр |
| | 6. Төрледән | | Мөдир |
| **5-нче киңәшмә** | **Тема: Еллык укыту-тәрбия эшен йомгаклау.** | май | |
| | 1. Һәр төркем тәрбиячесенең үз төркемендә укыту- тәрбия эшенә анализы.<br><br>2. Ел дәвамында уздырылган чаралар, төркемнәрдә укыту-тәрбия эшенә анализ.<br><br>3. Яңа уку елына укыту-тәрбия эше планының проекты белән танышу, фикер алышу. | | һәр төркем тәрбиячесе Өлкән тәрбияче |

## Квалификация күтәрү (2024- 2025 нче уку елы)

| № | Фамилиясе, исеме | Җаваплы кеше |
|---|---|---|
| 1. | Миназова Э.М. | Өлкән тәрбияче |
| 2. | Миндиярова Г.Р. | Өлкән тәрбияче |
| 3. | Муслихова Г.Ф. | Өлкән тәрбияче |
| 4. | Минязева Г.А. | Өлкән тәрбияче |

**2021-2028 елларда тәрбиячеләрнең  квалификацияне күтәрү курслары үтү графигы**

| Тәрбиячеләр исемлеге | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | 2026 | 2027 | 2028 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Галеева С.В. | 64 | | | 64 | | | 64 | |
| Гарипова С.Т. | | | 64 | | | 64 | | |
| Гиззатуллина Р.Р | 64 | | | 64 | | | 64 | |
| Миназова Э.М. | | 64 | | | 64 | | | 64 |
| Миндиярова Г.Р. | | 64 | | | 64 | | | 64 |
| Минязева Г.А. | | 64 | | | 64 | | | 64 |
| Муслихова Г.Ф. | | 64 | | | 64 | | | 64 |
| Насрутдинова А. | | | 64 | | | | | |
| Хасанова Г.А. | - | + | | 64 | | | 64 | |
| Симонова Л.Р. | | | 64 | | | | | |
| Валиуллина З.Т. | 64 | | | 64 | | | 64 | |

**Тәрбиячеләрнең аттестация үтү графигы**

| **Тәрбиячеләр исемлеге** | **2019-2020** | **2020-2021** | **2021-2022** | **2022-2023** | **2023-2024** | **2024-2025** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Галеева С.В. | | | | | + | |
| Гарипова С.Т. | + | | | | | + |
| Гиззатуллина Р.Р | | | | | | + |
| Миназова Э.М. | | | | | + | |
| Миндиярова Г.Р. | | | | | + | |
| Минязева Г.А. | | | | | | + |
| Муслихова Г.Ф. | | | | | + | |
| Насрутдинова А. | + | | | | | + |
| Хасанова Г.А. | | | | + | | |
| Симонова Л.Р. | + | | | | | + |
| Валиуллиан З.Т. | + | | | | + | |

**Контроль**

| № | Эш төре | Вакыты | Җаваплы кеше | Үтәлеш |
|---|---|---|---|---|
| | **Оператив тикшерү** | | | |
| 1 | Укыту-тәрбия көндәлек эш планнарының торышы | Даими | Өлкән тәрбияче | |
| 2 | Туклану культурасына анализ ясау (беренче һәм икенче кечкенәләр төркеме) | Ноябрь | Өлкән тәрбияче | |
| 3 | Педагогларның укыту методик комплектларны максатчан куллануны булдыру | Ноябрь | Өлкән тәрбияче | |
| 4 | Иртән һәм кич балаларның уен вакытын тикшерү. | Март | Мөдир, өлкән тәрбияче | |
| 5 | Тәрбиячеләрнең көндәлек эшчәнлегенә контрольлек итү | Апрель | Өлкән тәрбияче | |
| 6 | Җәйге уен мәйданчыкларының хәзерлеген булдыру Бакчаны, клумбаларны яшелләндерү өстендә эш. Яңа үсентеләр, чәчәкләр утырту. | Апрель- май | Мөдир, өлкән тәрбияче | |
| | **Тематик тикшерү** | | | |
| 1 | Балаларның сөйләм телен үстрү эшенең торышы | Октябрь | Өлкән тәрбияче | |
| 2 | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга патриотик тәрбия бирүнең нәтиҗәлеге | Февраль | Өлкән тәрбияче | |
| 3 | Балаларның мәктәпкә әзерлеген тикшерү | Апрель | Өлкән тәрбияче | |

**Конкурс, күргәзмәләр**

| № | Чаралар | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | «Шаҗәрә- Моя родословная»- күргәзмәсе | Сентябрь | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 2. | «Тылсымлы көз» Әти- әниләр белән берлектә эшләнгән күргәзмә | Октябрь | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 3. | «Минем әнием!» Әниләр көненә багышланган балалар рәсемнәре күргәзмәсе | Ноябрь | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 4. | Татарстан республикасы коституциясе көне (6 ноябрь) | Ноябрь | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 5. | «Кошлар ашханәсе» җимлекләр күргәзмәсе | Декабрь | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 6. | «Иң яхшы бүлмә бизәлеше»- төркменәрне яңа ел бәйрәменә әзерләү | Декабрь | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 7. | «Кышкы спортакиада» –кышкы уеннар, конкурслар | Январь | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 8. | «Батырлар даны мәңгелек»- М.Җәлил шигырьләрен сөйләү конкурсы | Январ- февраль | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 9. | «Минем яклаучым- Әтием» рәсем конкурсы | Февраль | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 10 | «Халыкара туган тел көне» (21 февраль) | Февраль | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 11 | «Әниемә бүләккә» балалар өчен рәсем конкурсы | Март | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 12 | «Кошларга оя ясыйк» әти- әниләр белән берлектә кошлар оялары ясау, конкурс. | Март | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 13 | «Тукай әкиятләре буенча сәяхәт» Г.Тукай әкиятләрен тасвирлау рәсем күргәзмәсе | Апрель | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 14 | Туган тел көне һәм татар шагыйре Г.Тукайның туган көне. (26 апрель) | Апрель | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 15 | «9 май- Җиңү йөзләре» Бөек Ватан сугышы геройлары, ветераннары зурлау, искә алу максатыннан, бабайларның фотолары белән күргәзмә. | Май | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 16 | 28 май- «Чик сакчылары көне»- паркка экскурсия, әңгәмә. | Май | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 17 | Тематик атналарга карата рәсем, апликация, күргәзмәләр | Ел дәвамында | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 18 | «Төсле меллар»- бакча ишегалдында асфальтта рәсемнәр ясау. | Июнь | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 19 | «Күңелле җәй»- рәсем конкурсы | Июнь | Өлкән тәрбияче, Тәрбиячеләр |
| 20 | «Бакчабызда җәйге олимпия уеннары»- спорт ярышлары. | Июнь | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 21 | 21 июнь- «Халыкара Әтиләр көне»- рәсем күргәзмәсе. | Июнь | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 22 | 22 июнь- «Хәтер һәм матәм көне» искә алу сәгате, әңгәмә. | Июнь | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 23 | «Гаиләм белән бәхетле мин»- Гаилә көне (8 июль) | Июль | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 24 | «Сабын куыгы көне» күңел ачу иртәсе. | Июль | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 25 | 12 август- физкультурниклар көне «Сәламәт тәндә- сәламәт акыл!» | Август | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 26 | 13 август «Төзүчеләр көненә» багышланган рәсем күргәзмәсе | Август | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 27 | 18 август- «Туган көнең белән – Лениногорск»- шәһәр паркына экскурсия | Август | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 28 | 22 август – Россия флагы көне. «Без бергә!»- әңгәмә, асфальтка рәсем ясау. | Август | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 29 | 30 август «Республикам минем- Татарстан»- шөгелләрдә тематик әңгәмә. | Август | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |

**Ата – аналар белән эш. Гомуми җыелышлар:**

| № | Эш төре | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| | I – җыелыш | | |
| 1. | Әти-әниләрне бакчаның еллык планы, уставы, бакча һәм гаилә арасындагы килешүнең эчтәлеге белән таныштыру. | Октябрь | Мөдир<br>Өлкән тәрбияче<br>Шәфкать туташы |
| 2. | Укыту-тәрбия эшендә яңа буын программаларын куллану ФДББ стандартлары белән танышу. | | |
| 3. | Әти-әниләргә бакчага түләү кагыйдәләре турында аңлату | | |
| 4. | Белем бирү һәм тәрбия бирүдә ике дәүләт теленең әһәмияте. | | |
| 5. | Сәламәтлек зур байлык. Консультация. | | |
| 6. | Фикер алышулар | | |
| | II – җыелыш: | | |
| 1. | Балагыз мәктәпкә бара.<br>Мәктәпкә хәзерлек төркеме балаларының хәзерлек дәрәҗәсе буенча информация,әти-әниләргә киңәшләр,методик ярдәм | Май | Мөдир<br>Өлкән тәрбияче<br>Шәфкать туташы |
| 2. | Узган уку елына анлаиз ясау. | | |
| 3. | Сәламәтлек карталары, мед.осмотр нәтиҗәләре. | | |
| 4. | Фикер алышулар | | |

**Бәйрәмнәр, күңел ачулар, ачык чаралар**

| № | Эш төре | Вакыты | Җаваплы тәрбияче |
|---|---|---|---|
| 1 | “Белем көне – 1 сентября”- күңел ачу иртәсе | Сентябрь | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе |
| 2 | “Сөмбелә бәйрәме” күңел ачу иртәләре | Октябрь | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе |
| 3. | «Өлкәннәр көне» бәйрәм иртәсе | Октябрь | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе |
| 4 | «Җәннәт әниләрнең аяк астында” бәйрәм иртәләре | Ноябрь | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе |
| 5 | «Яңа ел» бәйрәм иртәләре | Декабрь | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе |
| 6 | “Веселые колядки” күңел ачу | Январь | Тәрбяичеләр, рус теле тәрбиячесе |
| 7 | Кышкы уеннар “Зимние забавы” | | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе |
| 8 | “Ватанны саклаучылар көне”нә багышланган чара | Февраль | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе |
| 9 | “Муса Җәлил- Батыр даны мәңгелек!” бәйрәм иртәсе | | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе |
| 10 | “8 март-Халыкара хатын- кыз көне”нә багышланган иртә | Март | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе |
| 11 | “ А у нас – Масленица!” күңел ачу чарасы | | Тәрбяичеләр, рус теле тәрбиячесе |
| 12 | “Нәүрүз мөбәрәкбат!” кхңел ачу чарасы | | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе |
| 13 | “Хуш киләсез кошкайлар” бәйрәм иртәсе | Апрель | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе |
| 14 | “Путешествие в космос” бәйрәм иртәсе | | Тәрбяичеләр, рус теле тәрбиячесе |
| 15 | “Габдулла тукай- Бөек шагыйрь” бәйрәм иртәсе | | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе |
| 16 | «1 май- Карга боткасы!» күңел ачу чарасы | Май | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе |
| 17 | “9 май- Бөек җиңүгә 80 ел!” бәйрәм иртәсе | | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе |
| 18 | “Чыгарылыш кичәсе- 2025!” күңел ачу чарасы | | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе |
| 19 | “1 июнь- Балаларны яклау көне” –күңел ачу чарасы | Июнь | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 20 | “Күңелле сабантуйлар” күңел ачу чарасы | | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе |

**Административ-хуҗалык эшләре.**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | Гомүми җыелышлар:<br>-“Бакчаның хезмәтне саклау буенча эчке тәртип кагыйдәләрен беләсеңме?”<br>-Көзге бакча эшләрен кыска срокларда тәмамалау мәсәләсен карау.<br>- уку елына йомгак ясау | Сентябрь<br><br>Май | Мөдир |
| 2. | Тарификацияне вакытында һәм кыска срокларда үтү. | Сентябрь | Мөдир |
| 3. | Продукция һәм арзан материаллар отчетларын, хезмәткәрләрнең эшләгән һәм балаларның килгән көннәрен барлау ведомостьларын вакытында бухгалтериягә тапшырып бару. | Ел дәвамында | Мөдир |
| 4. | Эшчеләрнең ял итү графигын эшләү | Январь | Мөдир |
| 5. | Арзан һәм тиз тузучан материалларны гамәлдән чыгару, инвентарьларны исәпкә алу комиссиясе эшенә уңай җирлек тудыру. | Декабрь-апрель | Мөдир |
| 6. | Кышкы чорда бакчага килүче юлларны кардан чистартуны тәэмин итү. | Декабрь-март | Мөдир |
| 7. | Бакча территориясен язгы чистарту эшләрен оештыру | Апрель | Мөдир, барлык хезмәткәрләр |
| 8. | Агымдагы ремонт эшләренә йомгак ясау | Август | Мөдир |

**Балаларны юл кагыйдәләренә өйрәтү буенча эш планы**

| № | Чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплылар |
|---|---|---|---|
| 1 | Педагогларга консультация “Балаларга юл кагыйдәләрен өйрәтүне оештыру”<br>Переспектив планнар, программаларны һәм методик әсбапларны раслау | Август | Өлкән тәрбияче |
| 2 | Төркем бүлмәсендә һәм ата –аналар өчен “Юл йөрү кагыйдәләре” почмагын җиһазлау | Август | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 3 | Балалар һәм ата- аналар арасында “Без юл кагыйдәләрен хөрмәт итәбез”( «Мы с дорогою на Вы») рәсеме конкурсы | Сентябрь | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 4 | Макетлар конкурсы «Куркынычсыз урам чаты»<br>(«Безопасный перекрёсток») | Сентябрь | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 5 | Акция «Игътибар, балалар!»<br>(Внимание, дети!) | Сентябрь | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 6 | Табышмаклар – җаваплар кичәсе «Юл кагыйдәләрен беләбез» «Знают все мои друзья, знаю ПДД и я» | Сентябрь | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 7 | Бөтендөнья юл хәрәкәте корбаннарын искә алу көненә туры китереп акция үткәрү. «Йөрәгебезне саклап калыгыз»(«Сохрани наше сердечко») | Ноябрь | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 8 | Күңел ачу кичәсе «Юл билгеләре илендә» (« В стране дорожных знаков») | Февраль | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 9 | Юл кагыйдәләрен өйрәтү | Ел дәвамында режим кысаларында | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 10 | Юл кагыйдәләрен өйрәтү буенча дидактик уеннар ясау, күргәзмә әсбаплар сатып алу | Ел дәвамында | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 11 | Видеофильмнар карау | Ел дәвамында | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 12 | Рәсем ясау, әвәләү һәм кисеп ябыштыру. (Транспорт төрләре, шәһәр урамнары) | шөгыльләрдән тыш һәм буш вакытларда | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 13 | Матур әдәбият уку | шөгыль барышында һәм буш вакытларда | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 14 | Муниципаль чараларда катнашу | Ел дәвамында УО планы буенча | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |

**Балаларны җәйге сәламәтләндерү эше планы**

| № | Формасы | Үткәрү вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Җәйге чорга инструктаж | Май | Мөдир |
| 2 | Хезмәт коллективының җыелышы, җәйге сәламәтләндерү кампаниясенең бурычлары | Май | Мөдир, коллектив |
| 3 | Эшчеләрне беренчел ярдәм күрсәтү методларына өйрәтү (травмалар, агуланулар, зарарлы бөҗәкләр тешләве) | Май | Мөдир, коллектив |
| 4 | Санитар һәм гигиена таләпләре буенча, кояш һәм һава ванналары кабул итү өчен мәйданчыклар әзерләү | Даими, җәйнең азагына кадәр | Мөдир, коллектив |
| 5 | Юл кагыйдәләрен өйрәнү буенча ата – аналар катнашы белән гамәли шөгыльләр уздыру. | Июнь | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6 | “Сабантуй – 2025”  уеннары. Балалар һәм ата-аналар белән бергә “кул эшләреннән” күргәзмә. | Июнь | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 7 | “Табигать -  туган йортыбыз” дигән темага  ата-аналар белән сөйләшү. | Июнь | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 8 | Чәчәкләр бәйрәме | Июль | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 9 | Рәсемнәр күргәзмәсе | Июль | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 10 | Җәйге спортакиада | Июль | Өлкән тәрбияче, тәрбиячеләр |
| 11 | Кул эшләре өчен табигый материаллар җыю | Җәйнең азагына кадәр | Бөтен колектив һәм ата-аналар |

**Ата- аналар  комитетының эш планы**

| № | Эшнең эчтәлеге | Үткәрү вакыты | Җаваплылар |
|---|---|---|---|
| 1 | Устав, Балалар бакчасының коллдоговоры һәм эш планы белән танышу | Сентябрь | Комиссия әгъзалары |
| 2 | Ата-аналар комитетының  эш планын төзүдә катнашу | Октябрь | - |
| 3 | Гаиләнең тормыш-көнкүрешен , балаларны тәрбияләү шартларын өйрәнү | Ел барышында | - |
| 4 | Иң яхшы гаилә тәжрибәсен өйрәнү | Декабрь | - |
| 5 | Стендлар ясау:<br>“Баланы гаиләдә тәрбияләү”<br>“Ата-аналар – безнең ярдәмчеләр” | Ел барышында | - |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6 | Төркемнәрдә тәрбия, белем бирүне систематик тикшерү | Төркем җыелышларында | - |
| 7 | Төркемнәрдә тәрбия һәм белем бирүнең торышы турында ата-наларга мәгълүмат бирү | Ел барышында | - |
| 8 | Ата-аналар җыелышларында катнашу һәм уздыруга хәзерлек алып бару | Даими | - |
| 9 | Ата-аналар белән балалар мәйданчыгын җиһазлауда өмәләр оештыру | Ел барышында | - |
| 10 | Балалар бакчасында бәйрәмнәр үткәрүдә ярдәм итү | Ел барышында | - |
| 11 | Ата-аналар комитетының эшенә нәтиҗә ясауда катнашу (отчет) | Август | - |
| 13 | Ашату нормаларын тикшерү, контрольдә тоту | Даими | |
| 14 | Җиһазларны ремонтлауда булышу | Даими | |

**Бакчаның метериаль базасы**: Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе барлык кирәкле укыту җиһазлары белән тәэмин ителгән.
Белем бирү бурычларын тормышка ашыру максатыннан балалар бакчасы музыка залы, рус теле бүлмәсе, методик бүлмә заманча җиһаз һәм укыту-методик комплектлар белән тулыландырылган.
Балалар бакчасында 5 төркемдә 95 бала тәрбияләнә.

**Бакчаның балаларга белем һәм тәрбия бирүдә төп юнәлешләре:**

- Балаларга ике дәүләт телен өйрәтү эшчәнлегендә заманча технологияләр, укыту-методик комплектлар кулланып эшләү;
- Балаларның сәламәтлеген саклау, ныгыту, аларның физик һәм психик үсеше өчен мөмкинлекләр тудыру;
- Балаларга халык принципларына нигезләнеп, яңа педагогик алымнар кулланып, балаларга әхлак һәм патриотик тәрбия бирүне дәвам итү;
- Балаларга экологик тәрбия бирүне, экологик күнекмәләр формалаштыруны дәвам итү;
- Балалар бакчасы һәм гаиләнең хезмәттәшлеген арттыру.
- Балалар бакчасының төп бурычлары итеп милли-региональ компонентка таянып, милли мәдәният белүче һәм дәвам итүче шәхес формалаштыру һәм халык педагогикасы принципларны нигезләнеп, яңа педагогик алымнар кулланып балаларга әхлак һәм патриотик тәрбия бирү торалар. Бу ике юнәлеш бер-берсен тулыландырып, үрелеп алып барыла.

**Әйләнә-тирә мохит**. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе шәһәрнең үзәгендә урнашкан. Балалар бакчасының уң ягында китап кибете, сул ягында күпкатлы йортлар. Балалар бакчасы арткы урамында 2 нче урта гимназия урнашкан. Шәһәребездә 32 балалар бакчасы булуына карамастан бакчага йөрүче балалар саны нормада. Балаларның бакчага күп булып йөрүе балалар бакчаның ныклы материаль базасы булуында. Балалар бакчасы шәһәребездә гомуми 11 нче татар гимназиясе, балалар китапханәсе, мәдәният йорты балалар иҗади үзәге, музей белән тыгыз элемтәдә тора.

Кадрлар белән тәэмин ителү. Балалар бакчасының мөдире Низамова Гөлфия Яхия кызы, югары белемле, педагогик стажы 45 ел. Өлкән тәрбияче югары белемле, педагогик стажы - 14 ел. Бакчабызда 11 тәрбияче хезмәт куя. Балалар бакчасында тәрбиячеләрдән педагог-

психолог, музыка җитәкчесе, рус теле тәрбиячесе бар. План нигезендә тәрбиячеләрнең һөнәри осталыкларын арттыру буенча эзлекле эш алып барыла. Тәрбиячеләр педагогик киңәшмә утырышларында үзләренең яңа укыту-методик комплектлар белән эшләү буенча эш тәҗрибәләре белән бик теләп уртаклашалар, киңәшләшәләр. Шулай ук тәрбиячеләр район, республика күләмендә узган балаларны ике дәүләт теленә өйрәтү буенча семинарларда теләп эш тәҗрибәләре белән уртаклашалар. Педагогик коллективка яшь тәрбиячеләр өстәлделәр. Алар үзләренең эш стажлары аз булуына карамастан, тырышып эшлиләр, өлкәнрәк яшьтәге остазлардан өйрәнәләр.

Балалар бакчасы базасында район һәм республика күләмендәге семинарлар бик уңышлы үтәләр.

Белем бирү процессы. Балалар бакчасында белем бирү процессы федераль белем бирү программасы нигезендә төзелде.

Парциаль программалар:

Ф.В.Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова “Туган телдә сөйләшәбез” 2-3 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, Казан “Фолиант”, 2012;

Ф.В.Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова “Туган телдә сөйләшәбез” 3-4 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек Казан “Фолиант”, 2012;

Ф.В.Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова “Туган телдә сөйләшәбез” 4-5 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, Казан “Фолиант”, 2012;

З.М.Зарипова, Л.Н.Вәҗиева “Туган телдә сөйләшәбез” 5-7 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, Казан “Фолиант”, 2012;

С.М.Гаффарова, Д.С.Гарипова “Изучаем русский язык” методическое пособие для воспитателей детских садов 4-5 лет, 5-6 лет, 6-7 лет.

С.М.Гаффарова, Д.С.Гарипова “Изучаем русский язык”: программа, методические рекомендации, диагностика, Казань, 2013;

Р.К.Шаехова Мәктәпкәчә балалар әлифбасы: “Авазларны уйнатып” , Казан,2011.

К.В.Закирова “Балачак аланы”, балалар бакчалары тәрбиячеләре өчен хрестоматия, Казан, 2011.

К.В.Закирова “На поляне детства”, хрестоматия для воспитателей детских садов, Казан, 2011.

К.В.Закирова, Л.Р.Мортазина “Әй уйныйбыз, уйныйбыз”, балалар бакчалары тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма, Казан, 2013;

З.М.Зарипова “Үстерешле уеннар”, Казан, 2013

З.М.Зарипова, А.Х.Габдрахимова “Балалар бакчасында бердәм белем бирү эшчәнлеге”, Казан, 2013;

М.Ф.Кашапова «Балалар бакчасында сөйләм үстерү программасы»,
Казан, 2004.

Программа по обучению детей русскому языку г.Набережные Челны,2004

Л.Д.Глазырина «Методика физического воспитания детей дошкольного возраста», Москва, 1999.

К.В.Закирова «Гаиләдә, балалар бакчасында әдәплелек тәрбияләү программасы” , Казан,2005.

Р.К.Шаехова “Иҗади уеннан – укуга”.

С.Н.Николаева «Юный эколог», 2006.

Р.А.Борһанова “Туган як табигате белән таныштыру”.

Е.В.Колесникова “Математика для детей 4-5 лет”.

Е.В.Колесникова “Математика для детей 5-6 лет”.

Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет”.

Укыту-методик комплектлар:

татар балаларын  туган телендә сөйләшергә өйрәтү - «Туган телдә сөйләшәбез» (җитәкче Хазратова Ф. В.) - методик кулланма, эш дәфтәрләре, күрсәтмә һәм таратма материал;

- татар балаларын рус теленә өйрәтү - «Изучаем русский язык» (җитәкче Гаффарова С.М.) - методик кулланма, эш дәфтәрләре, күрсәтмә һәм таратма материал, балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия, аудио һәм видеоматериал, мультимедиа;
- мәктәпкә әзерлек төркеме балаларын грамотага өйрәтү -  «Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы: авазларны уйнатып» (татар балалары өчен) һәм  «Раз – словечко, два - словечко» кулланмасы, автор Шаехова Р. К. - , эш дәфтәрләре, тәрбиячеләр өчен  методик рекомендацияләр, тәрбиячеләр һәм әти-әниләр өчен методик кулланма.

Дисклар.

1.“Уйный-уйный үсәбез” 5яшь.
2.“Без иде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” , 6-7яшь.
3.Союзмультфильмнар №1.
4.Союзмультфильмнар №2.
5.Союзмультфильмнар №3.
6.«Болтливая утка”.
7.“Африканские приключения”.
8.“Бииләр читекләр”.
9.“Эх, пляшут наши сапожки”.
10.“Татарча сөйләшәбез” 4-5яшь.
11.“Шома бас”.
12.Мультимедийный проект.
13. Мультфильмы на татарском языке.

Балалар бакчасында кулланылган программалар мәктәпкәчә яшьтәге балаларда гомуми культура хәзинә үрнәкләре формалаштыру, физик, интеллектуаль, шәхси сыйфатлар тәрбияләүгә, балаларның сәламәтлеген саклауга һәм ныгытуга юнәлтелгән.

Балалар бакчасында укыту процессын оештыруда заманча формалар кулланыла: бердәм эшчәнлек төркемнәрдә һәм индивидуаль алып барыла. Мондый формаларны куллану тәрбиячегә, белем бирү максатларын,  балага якын килеп,  аның эшләү дәрәҗәсен, үзләштерү тизлеген исәпләп, төзергә мөмкинлек бирә.

«Инновацион белем бирү технологияләрен куллану аша мәктәпкәчә белем бирү эчтәлеген яңарту» резолюциясе нигезендә 2012нче елның 1 сентябреннән Татарстан Республикасы балалар бакчаларында мәктәпкәчә яшьтәге балаларга ике дәүләт телен өйрәтү максатыннан яңа укыту-методик комплектлар кулланылышка кертелде.

Педагоглар балаларда  кешелеклелек сыйфатлары тәрбияләүгә, табигать доньясына, кешеләргә ихтирам һәм хөрмәт тәрбияләүдә бар тырышлыкларын куеп эшлиләр. Бакча педагогларының яшь буын тәрбияләүдә иң мөһим бурычларның берсе – баланың социаль-шәхси үсеше.

Балалар бакчасында предметлы-үстерешле тирәлекне яңарту процессы  бара.  Уен һәм дидактик материалның уңайлы һәм урынлы урнаштырылуы балаларга төрле эшчәнлекләр белән шөгыльләнү өчен зур мөмкинлекләр тудыра.

Уен – балаларның төп эшчәнлеге. Уен вакытында булачак шәхеснең нигезләре салына. Бу үзенчәлекне исәпкә алып, төркемнәрдә : «Матурлык салоны», «Супермаркет», «Шифаханә»  һ.б.уен почмаклары булдырылды.

Балаларга эстетик тәрбия бирү буенча эшчәнлек тәрбия процессының төрле яклары белән бәйләнгән. Педагоглар балаларда уен, хезмәт эшчәнлегендә матур әдәбият һәм сәнгать әсәрләре аша эстетик зәвык тәрбиялиләр.

Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә **музыкаль-сәнгать эшчәнлегенә** аерым игътибар бирелә.

Бакчаның музыка җитәкчесе музыкаль белем бирү процессына иҗади якын килеп, балалар белән эшләүдә кызыклы алымнар кулланып һәр балага аерым якын килеп, балаларның төрле яклап тиешле югарылыктагы музыкаль белем алуларын тәэмин итә. Шундый максатчан эш нәтиҗәсендә бакчада тәрбияләнеп чыккан балаларның күбесе белем алуларын Сәнгать мәктәбендә дәвам итәләр, район Мәдәният йортында оештырылган җыр, бию түгәрәкләренә йөриләр.

Бакчада «Карга боткасы», «Гаиләм- зур байлыгым!», «Сабантуй», «Нәүрүз», «Әти, әни, мин – спорт гаиләсе», «Яңа ел» иртәсе , «Әнием-алтыным», «Әти белән көчле мин!», «Сөмбелә», «Җиңү бәйрәме», « Күңелле Светофор» һ.б. бәйрәмнәр, күңел ачу иртәләре билгеләп үтелә. Балалар өчен курчак театрлары, сәламәтлек көннәрен бергәләп бәйрәм итү бик матур гадәткә әйләнде.

Балаларның **сынлы сәнгатьтә иҗади** сәләтләрен үстерүгә зур игътибар бирелә. Классик рәссамнарның әсәрләре белән, халыкларның декоратив-гамәли сәнгате үрнәкләре белән танышалар.

Нәфасәти эшчәнлектә төрле технологияләр, алымнар куллануга, композиция, материал, сюжет сайлауга ирек бирү, балага үз-үзен күрсәтә алуга мөмкинлек бирә, иҗат итү һәм танып белү сәләтен үстерү.

План нигезендә башкарылган максатчан эш нәтиҗәсендә балаларыбыз рухи яктан баедылар, аларның иҗат мөмкинлекләре ачылды, нәфасәти эшчәнлекләрдә уңай күнекмәләр формалашты.

**Сәламәтләндерү эше.**

Физкультура-сәламәтләндерү эшен дөрес оештыру нәтиҗәсендә балаларның авыру очраклары күрсәткече сизелерлек кимеде. Бу тотрыклы күрсәткечнең төп факторлары булып түбәндәгеләр тора:

- медицина кабинеты булуы;
- спортмәйданчыгы булуы;
- мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең медицина кадры белән тәэмин ителеше (шәфкать туташы)

Балалар арасында авырулар очракларын киметү максатыннан сезонлы тын юллары авырулары кискенләшкән вакытларда, профилактика чаралары үткәрелә: фитотерапия, поливитаминннар кабул итү, чыныктыру чаралары, үз-үзеңне массажлау, сулыш гимнастикасы ясау. Физик культура эшчәнлегендә баланың умыртка баганасын дөрес формалашырга ярдәм итәрлек күнегүләр кертелә. Табиблар (педиатрлар) күзәтүендә 5-7 яшьлек балаларның диспансеризация үтүенә зур игътибар бирелә. Нинди дә булса патологияләр ачыкланса сәламәтләндерү буенча чаралар билгеләнә.

**Әти-әниләр белән эш**. Белем бирү процессында катнашучыларның берсе булып тәрбияләнүчеләрнең әти-әниләре (законлы вәкилләр) тора. Алар арасындагы мөнәсәбәт гамәлдәге законга, балалар бакчасы Уставына, әти-әниләр һәм балалар бакчасы арасындагы килешүгә таянып, җайга салына. Әти-әниләр һәм балалар бакчасы арасындагы килешү һәр гаилә белән аерым төзелә, һәм ул баланың бакчада булган вакытында уңай шартлар тудырырга һәм аның индивидуаль узенчәлеген, мөмкинлекләрен, әти-әниләрнең таләпләрен, теләкләрен исәпкә алып, белем бирү өлкәләренең барлык төрен тәкъдим итүне гарантияли. Безнең балалар бакчасында әти-әниләргә белем бирү процессына, тәрбия чараларына катнашырга, тәрбияче белән балаларның эшчәнлеге барышында, режим моментларына ирекле рәвештә керергә мөмкинлекләр бирелә. Тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре белән традицион формадагы эшләр: консультацияләр, очрашулар, әңгәмәләр, җыелышлар тәрбия өлкәсендә билгеле бер нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирә.

Хәзерге вакытта җитәкчелекнең, бакча педагогларының, әти-әниләрнең тыгыз элемтәдә булуы, бердәм эшчәнлек алып баруы бигрәк әһәмиятле. Моны тормышка ашыру максатыннан яңа төр эшчәнлек формаларын әти-әниләргә тәкъдим итәбез: күргәзмәләр, бергә оештырган спорт бәйрәмнәре. “Ачык ишекләр көннәре”, әти-әниләр белән балаларның бергә ясаган иҗади эшләр күргәзмәләре. Өлкәннәр

белән балаларның бердәм эшләве, аларның дусларча тыгыз элемтәдә булуы, алар арасында уртак кызыксыну булу – балада эмоциональ комфорт тудыра.

Әти-әниләрнең балалар бакчасында көнлек режим, туклану, сәламәтләндерү, белем бирү, күңел ачу эшчәнлекләре, баланың бакчадагы яшәү шартлары, аларның бакчага карата мөнәсәбәте, педагогларның һөнәри осталыклары хакында булган фикерләрен өйрәнгәннән соң түбәндәгеләр ачыкланды: әти-әниләр бакча коллективына. Аның җитәкчелегенә ышаныч белдерәләр һәм гомумән алганда балалар бакчасының эшчәнлегеннән бик кәнәгать.

Күпчелек әти-әниләр эш нәтиҗәләре белән кызыксыналар, ләкин гаилә белән бакча арасындагы бердәм эшчәнлекнең әһәмиятен тулысынча аңлап җиткермиләр, шуның өчен дә белем бирү процессына тиешенчә катнашып, кереп китә алмыйлар. Шулай итеп, балаларга белем бирүдә бердәм тырышлыкның көчен аңлап уңай нәтиҗәләргә ирешергә теләүче әти-әниләр белән җитәрлек дәрәҗәдә кызыксынмаган, белем бирү өлкәсенең асылына төшенеп җитмәгән әти-әниләр арасында күпмедер каршылыклар килеп чыга. Бу проблема чишүне балалар бакчасында, гаиләләрдә заманча таләпләргә туры килгән традицион булмаган эш ысулларын кулланып, аларга таянып, дәвамлы рәвештә хәл итәчәкбез. Ә моның өчен тәрбияләнүче балаларның әти-әниләре белән  партнерлык мөнәсәбәтне үстерүне үз югарылыгына җиткерергә кирәк.

**Башка оешмалар белән элемтә**.

Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе шәһәребездәге 11нче татар гимназиясе , шәһәр музее, балалар китапханәсе, Г.Тукай исемендәге үзәк китапханә белән тыгыз элемтәдә тора. Шулай ук район үзәгенең культура-агарту үзәкләре белән дә бердәм эшләр алып бара. Алар белән хезмәттәшлек итү  мәктәпкәчә мәгариф системасына куелган яңа таләпләрдә уңышлы ориентлашырга, үзенең эшчәнлеген психология һәм педагогика өлкәсендәге казанышларны һәм социум таләпләрен искә алып,   вакытында коррекцияләргә мөмкинлек бирә. Шәһәр мәдәният үзәгендә, сәнгать мәктәбендә үткәрелгән чараларда катнашу балаларның эмоциональ һәм эстэтик кичерешләрен баета.